ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСЕНБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСӘНБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2019 Исәнбай авылы № 10

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегендә нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында

Исәнбай авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 20 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә, 1993 елның 11 февралендәге 4462-I номерлы нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 16.1 статьясына һәм нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда түбәндәге нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә:

1.1. кучемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләрдән тыш, ышаныч кәгазе таныклыгы бирү;

1.2. мирас мөлкәте исемлеген төзү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрү;

1.3. документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын таныклау;

1.4. документларда имзаның чынлыгын таныклау;

1.5. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклау;

1.6. гражданинның исән булу факты таныклау;

1.7. тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалид затның үз кулы белән куйган имзаның факсимиль рәвештә куелган имза белән тәңгәл булуын таныклау;

1.8. гражданинның билгеле урында булу фактын таныклау;

1.9. теге яки бу затның фотографиядә сурәтләнгән граждан белән тәңгәл булуын таныклау;

1.10. документлар тапшыру вакыты таныклау;

1.11. теге яки бу кәгазь документның электрон документ белән тәңгәл булуын таныклау;

1.12. теге яки бу электрон документның кәгазь документ белән тәңгәл булуын таныклау.

2. РФ Юстиция министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма һәм тәртип буенча исәпкә алынучы әлеге карарның беренче өлешендә күрсәтелгән җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары турында белешмәләрне РФ Юстиция министрлыгының территориаль органына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Ф.Ф. Сираев